| МИНИСТЕРСТВО ТРУДА, ЗАНЯТОСТИ И СОЦИАЛЬНОЙ ЗАЩИТЫ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ХЕЗМӘТ, ХАЛЫКНЫ ЭШ БЕЛӘН ТӘЭМИН ИТҮ ҺӘМ СОЦИАЛЬ ЯКЛАУ МИНИСТРЛЫГЫ |
|---|---|

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

29.05.2024 Казан ш № 388

Татарстан Республикасында күпбалалы гаилә статусын билгеләү тәртибе турында

1. Татарстан Республикасында күпбалалы гаилә статусын билгеләү тәртибен (кушымтада бирелә) расларга.

2. Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының түбәндәге боерыкларын көчен югалткан дип танырга:

«Күпбалалы гаилә статусын билгеләү турында (Татарстан Республикасында күпбалалы гаилә таныклыгын бирү, аның гамәлдә булу вакытын озайту һәм алмаштыру)» 04.09.2012 №697;

«Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Татарстан Республикасында күпбалалы гаилә таныклыгын рәсмиләштерү һәм бирү тәртибе турында» 2012 елның 4 сентябрендәге 697 номерлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасында күпбалалы гаилә таныклыгын рәсмиләштерү һәм бирү тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында» 16.09.2013 №529 ;

«Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Татарстан Республикасында күпбалалы гаилә таныклыгын рәсмиләштерү һәм бирү тәртибе турында» 2012 елның 4 сентябрендәге 697 номерлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасында күпбалалы гаилә таныклыгын рәсмиләштерү һәм бирү тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында» 17.05.2021 №313;

«Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Татарстан Республикасында күпбалалы гаилә таныклыгын рәсмиләштерү һәм бирү тәртибе турында» 2012 елның 4 сентябрендәге 697 номерлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасында

күпбалалы гаилә таныклыгын рәсмиләштерү һәм бирү тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында» 23.05.2022 №398;

«Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының аерым боерыкларына үзгәрешләр кертү турында» 28.08.2023 №702.

3. Әлеге боерык үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министры урынбасары Н.Б.Бутаевага йөкләргә.

Министр Э.Ә. Зарипова

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 2024 елның «29» маендагы 388 номерлы боерыгы белән расланды

Татарстан Республикасында күпбалалы гаилә статусын билгеләү тәртибе

1. Татарстан Республикасында күпбалалы гаилә статусын билгеләүнең әлеге тәртибе Татарстан Республикасында күпбалалы гаилә статусын билгеләү кагыйдәләрен билгели (алга таба – Тәртип).

2. Составы әлеге Тәртипнең 3 һәм 4 пунктлары нигезендә билгеләнә торган күпбалалы гаилә статусын билгеләү Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының социаль яклау идарәсе (бүлеге) (алга таба – Идарә (бүлеге)) тарафыннан күпбалалы гаиләнең ата-анасының Татарстан Республикасында яшәү урыны (алга таба – мөрәҗәгать итүче) буенча гамәлгә ашырыла, анда кимендә өч баланың Татарстан Республикасында яшәү (тору) урыны булырга тиеш.

Әлеге Тәртипнең гамәлләре түбәндәгеләргә кагыла:

а) «Күпбалалы гаиләләргә социаль ярдәм чаралары турында» Россия Федерациясе Президентының 2024 елның 23 гыйнварындагы 63 номерлы Указы (алга таба – РФ Президентының 63 номерлы Указы) үз көченә кергән көннән күпбалалы дип танылган гаиләләргә;

б) РФ Президентының 63 номерлы Указы үз көченә кергән көнгә кадәр күпбалалы дип танылган һәм РФ Президентының 63 номерлы Указы үз көченә кергән көнгә әлеге статусын югалтмаган гаиләләргә;

в) Россия Федерациясе субъектларының норматив хокукый актлары нигезендә күпбалалы гаилә статусын югалткан һәм РФ Президентының 63 номерлы Указының 1 һәм 2 пунктлары нигезләмәләренә туры килгән гаиләләр.

3. Күпбалалы гаилә статусын билгеләгәндә, күпбалалы гаилә составында, күп балалы гаиләнең барлык әгъзалары Россия Федерациясе гражданнары булу шарты белән, фактта яшәүче һәм 18 яшькә кадәрге һәм (яки), белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы оешмада көндезге уку формасы буенча белем алу шарты белән, 23 яшькә кадәрге, шул исәптән тәрбиягә алынган (уллыкка алынган) балаларын, үги ул-кызларын тәрбияләүче ир белән хатын, белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы оешмада укулары белән бәйле рәвештә, ата-аналардан аерым яшәүче балаларның күрсәтелгән категорияләре исәпкә алына.

4. Күпбалалы гаилә составына кертелми:

ата-аналары яки бердәнбер ата-анасы ата-ана хокукларыннан мәхрүм ителгән балалар;

эмансипация яки гаилә кору сәбәпле тулы күләмдә эшкә сәләтле балалар.

5. Күпбалалы гаилә статусын билгеләү турында гаризаны мөрәҗәгать итүче яки ышаныч кәгазе нигезендә эш итүче вәкаләтле зат аның яшәү (тору) урыны буенча Идарәгә (бүлеккә) бирә:

электрон рәвештә Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең (функцияләрнең) бердәм порталын, шулай ук Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталын кулланып;

дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәге аша;

почта аша җибәрү юлы белән;

гомуми файдаланудагы мәгълүмат-телекоммуникация челтәрләре, шул исәптән «Интернет» челтәре аша;

шәхсән.

Идарәдә (бүлектә) күпбалалы гаилә статусын билгеләү турында теркәлгән гариза булганда, ул шул ук мөрәҗәгать итүче тарафыннан кабат бирелгән булса, гариза каралмый.

6. Мөрәҗәгать итүченең тормыш хәленә карап, гаризага түбәндәге документлар теркәлә:

баланың тууын теркәү турындагы таныклыкның чит дәүләтнең компетентлы органы тарафыннан бирелгән күчермәсе һәм аның нотариаль яктан расланган рус теленә тәрҗемәсе;

гаилә кору турында чит дәүләтнең компетентлы органы тарафыннан бирелгән таныклык күчермәсе һәм аның нотариаль яктан расланган рус теленә тәрҗемәсе;

аерылышу турында чит дәүләтнең компетентлы органы тарафыннан бирелгән таныклык күчермәсе һәм аның нотариаль яктан расланган рус теленә тәрҗемәсе;

ир белән хатын аерылышкан очракта, баланың (балаларның) яшәү урынын билгеләү турында законлы көченә кергән суд карары күчермәсе;

көндезге уку формасы буенча белем бирү эшчәнлеген алып баручы оешмада 18 яшьтән 23 яшькә кадәрге баланы укыту факты турында белешмә;

чит ил территориясендә бирелгән Россия Федерациясеннән читтә уку турында документ һәм аның рус теленә нотариаль расланган тәрҗемәсе;

шәхси мәгълүматны эшкәртүгә ризалык һәм башка ата-ана тарафыннан тарату өчен рөхсәт ителгән шәхси мәгълүматны эшкәртүгә ризалык.

Мөрәҗәгать итүче мөрәҗәгать иткәндә шәхесен таныклаучы документны күрсәтә.

Документларның күчермәләре, әгәр алар Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә таныкланмаган булса, төп нөсхәләре белән бергә күрсәтелә һәм Идарә (бүлек) белгече тарафыннан таныклана. Документларның күчермәләре бер нөсхәдә тапшырыла.

Гариза Идарәгә (бүлеккә) почта буенча җибәрелергә мөмкин. Бу очракта гаризага документларның Россия Федерациясе законнары нигезендә таныкланган күчермәләре теркәлә.

Мөрәҗәгать итүче тапшырылган документларның дөреслеге өчен Россия Федерациясе законнары нигезендә җаваплы.

7. Идарә (бүлек) ведомствоара рәсми мөрәҗәгатьләр нигезендә, шул исәптән

электрон формада да, ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек системасыннан файдаланып, вәкаләтле органнардан түбәндәге мәгълүматларны ала:

бала туу турында;

никахлашу (аерылышу) турында;

мөрәҗәгать итүченең һәм балаларның Россия Федерациясе чикләрендә яшәү урыны буенча теркәлү булу-булмавы турында;

ата-ана хокукыннан мәхрүм ителү турында;

18 яшьтән 23 яшькә кадәрге баланы гомуми белем бирү оешмасында укыту турында;

гражданин паспортының чынлыгы турында.

Мөрәҗәгать итүчеләр үз инициативалары буенча Идарәгә (бүлеккә) әлеге Тәртипнең әлеге пунктында күрсәтелгән мәгълүматлар булган документларны тапшырырга хокуклы.

8. Күпбалалы гаилә статусын билгеләү (билгеләүдән баш тарту) турында карар күпбалалы гаилә статусын билгеләү турында гариза теркәлгән көннән алып 10 эш көне эчендә Идарә (бүлек) тарафыннан кабул ителә.

Күпбалалы гаилә статусын билгеләү (билгеләүдән баш тарту) турында кабул ителгән карар турында мөрәҗәгать итүчегә гаризада күрсәтелгән телефонга СМС-хәбәр белән күпбалалы гаилә статусын билгеләү (билгеләүдән баш тарту) турында карар кабул ителгән көннән алып бер эш көне эчендә җиткерелә.

9. Күпбалалы гаилә статусын билгеләүдән баш тарту өчен нигез булып түбәндәгеләр тора:

әлеге Тәртипнең 2 пунктында билгеләнгән таләпләргә туры килмәгән затның мөрәҗәгать итүе;Р59

дөрес булмаган белешмәләре булган документларның тапшырылуы;

мөрәҗәгать итүченең һәм өч баланың Татарстан Республикасы территориясендә яшәү (тору) урыны булмавы;

мөрәҗәгать итүче тәкъдим иткән документларның формасы яки эчтәлеге буенча әлеге Тәртиптә билгеләнгән таләпләргә туры килмәве;

Россия Федерациясе Президентының «Күпбалалы гаиләләргә социаль ярдәм чаралары турында» 2024 елның 23 гыйнварындагы 63 номерлы Указына ярашлы рәвештә билгеләнгән күпбалалы гаилә статусы турында мәгълүмат булу;

мөрәҗәгать итүченең һәм (яки) аның гаилә әгъзаларының әлеге Тәртипнең 3 пунктында билгеләнгән таләпләргә туры килмәве;

әлеге Тәртипнең 4 пунктында күрсәтелгән шартларның булуы.